РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАМАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423643, РТ, Менделеевский район,
с.Камаево, ул. Дифгата Сирая д.29А

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КАМАЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423643 , РТ, Менделеевск районы,
Камай авылы, Дифгать Сирай урамы
29А йорты

Тел./ факс: 8(85549) 3-55-33, E-mail: Kam.Men@tatar.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

2026 елның 27 нче мартыннан № 23

Татарстан Республикасы Менделеевск
муниципаль районы Камай авыл җирлеге
Советының 2024 елның 17 июнендәге
«Физик затлар мөлкәтенә салым турында»
120 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 28.11.2025 № 425-ФЗ Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 17.06.2024 № 120 карарына (алга таба - Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 2.4 пунктчасындагы 4 абзацтагы карарларны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“- һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган салым салу объектлары, проектлана торган билгеләнеше күпфатирлы йорт булган төзелеп бетмәгән объектлардан тыш».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән, әмма әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән кимендә бер ай узгач үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Менделеевск муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге www.mendeleevsk.tatar.ru веб-адрес буенча Камай авыл җирлеге бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырып халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге Советының Җирле үзидарә һәм финанс-бюджет мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә..

Камай авыл җирлеге Советы рәисе И. М. Ахунҗанов